ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ АГРЫЗСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ул. Гагарина, д.13, г. Агрыз, 422230

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ӘГЕРҖЕ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

Гагарин ур.,13, Әгерҗе шәһәре, 422230

Тел.: (85551) 2-22-46; Факс: 2-22-46; E-mail: isp.agryz@tatar.ru; www. agryz.tatarstan.ru

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

«12» июль 2019 ел. № 285

Мәктәп автобуслары маршрутларын раслау турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының "Мәктәп автобусларын файдалануның нәтиҗәлелеген тәэмин итү максатларында мәктәп автобус маршрутын ачу турындагы нигезләмәне раслау хакында"гы 2010 ел, 3 август, 615 нче карары нигезендә Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Башкарма комитеты,

КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Башкарма комитетының 2019 елның 15 гыйнварыннан 07 номерлы “Мәктәп автобуслары маршрутларын раслау турында”гы карары белән расланган №12 «Тирсә-Яңавыл-Тирсә-Кодаш-Биектау-Тирсә», № 6 «Тирсә-Вольный Труд-Нажар-Чишмә-Тирсә-Биектау-Мордыбый-Тирсә-Тоба-Тирсә», №11 «Тирсә-Бәзәкә-Вольный Труд-Тирсә-Мордыбый-Чишмә-Тирсә» мәктәп маршрутларының гамәлдә булуын туктатырга.

2. 12 нче номерлы «Тирсә-Яңавыл- Вольный Труд -Тирсә-Кодаш-Тирсә», 6 нчы номерлы «Тирсә-Яңавыл-Тирсә-Биектау-Мордыбый-Тирсә-Нажар-Чишмә-Тирсә», 11 нче номерлы «Тирсә-Бәзәкә-Яңавыл-Тирсә-Мордыбый-Тирсә-Тоба-Тирсә» автобус маршрутларын ачарга.

3. "Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы мәгариф идарәсе” муниципаль казна учреждениесенә (В. Г. Сафиуллинага):

- Мәктәп автобус маршрутын ачу турындагы Нигезләмәгә таянып, 12 нче номерлы «Тирсә-Яңавыл- Вольный Труд -Тирсә-Кодаш-Тирсә», 6 нчы номерлы «Тирсә-Яңавыл-Тирсә-Биектау-Мордыбый-Тирсә-Нажар-Чишмә-Тирсә», 11 нче номерлы «Тирсә-Бәзәкә-Яңавыл-Тирсә-Мордыбый-Тирсә-Тоба-Тирсә» мәктәп автобус маршрутларының паспортын эшләргә, килештерергә һәм расларга;

- Мәктәп автобус маршрутлары реестрына тиешле үзгәрешләр кертергә;

- иртәнге һәм дәрестән тыш вакытта автобуслар хәрәкәте графигын эшләргә һәм ел саен анықларга;

- Россия Эчке эшләр министрлыгының Әгерҗе районы буенча ЮХИДИ бүлеге белән килештереп, укучыларны утырту һәм төшерү пунктларын билгеләргә.

4. Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Тирсә урта гомуми белем бирү мәктәбендә (Л. И. Каримова) балаларны уку урынына алып кайтканда озата бару һәм кире кайтару өчен җаваплы башкаручыны билгеләргә.

5. Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Финанс-бюджет палатасына (А. Н. Бадахшин) Татарстан Республикасы бюджетыннан бүлеп бирелә торган субсидияләр хисабына укучыларны мәктәп автобуслары белән йөртүне оештыру чыгымнарын финанслауны тәкъдим итәргә.

6. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга

7. Карарның үтәлешен контрольдә тотуны Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең беренче урынбасары Р.Р. Гильмутдиновага йөкләргә.

**Җитәкче** **А.С. Авдеев**